КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 26 май г.Казань № 401

Казан шәһәрендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын әзерләү һәм үткәрү чорында радиациядән, химик куркыныч матдәләрдән һәм биологик саклануны һәм аларны тикшерүдә тотуны оештыру турында

Казан шәһәрендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын (алга таба – дөнья чемпионаты) әзерләү һәм үткәрү чорында радиациядән, химик куркыныч матдәләрдән һәм биологик саклануны һәм аларны тикшерүдә тотуны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

радиациядән, химик куркыныч матдәләрдән һәм биологик саклануны һәм аларны тикшерүдә тоту көчләре төркемнәре составын;

радиация характерындагы, химик һәм биологик характердагы хәлләр (гадәттән тыш хәлләр) барлыкка килгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары белән федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары һәм оешмалар хезмәттәшлеге тәртибен.

2. Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына, Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Россия Федерациясе Эчке эшләр

министрлыгының Казан транспорт линия идарәсенә, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә, Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсенә караган Татарстан таможнясына, Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсенә, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенә, «Татарстан Республикасының Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохит мониторингы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә, «Татар төбәкара ветеринария лабораториясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенә, «Росатом» дәүләт коорпорациясенең «РосРАО» радиоактив калдыклар белән эш итү предприятиесе» федераль дәүләт унитар предприятиесенә караган «Идел буе территориаль округы» филиалының Казан бүлегенә, Татарстан Республикасының күзәтү һәм лаборатория тикшерүе челтәре составына керүче Казан шәһәре учреждениеләренә, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасына, дөнья чемпионаты объектлары һәм базасында гражданнар оборонасы объектлары төзелгән Татарстан Республикасы оешмалары, радиацияле, химик һәм биологик куркыныч объектлар, аэропортлар, автовокзаллар, елга портлары һәм тимер юл станцияләре җитәкчеләренә (милекчеләренә) аларны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

үз вәкаләтләре кысаларында радиация, химик һәм биологик торышны мониторинглауны;

Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең территориаль ярдәмче системасындагы көндәлек идарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итүне һәм бу карар белән расланган радиациядән, химик куркыныч матдәләрдән һәм биологик саклануны һәм аларны тикшерүдә тоту көчләре төркемнәре составына көчләр һәм чаралар бирүне;

Казан шәһәре территориясендә урнашкан радиацияле, химик һәм биологик куркыныч объектларда зарарлану, җимерелү (һәлакәтләр булу) шартларында, шулай ук дөнья чемпионаты объектларында яки кешеләр күпләп булу урыннарында мөмкин булган терроризм актлары аркасында мөмкин булган гадәттән тыш хәлләргә үз вакытында җавап бирүне һәм аларны бетерү барышында куелган бурычларның үтәлешен тәэмин итүне.

3. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына медицина оешмаларында гадәттән тыш хәлләр очракларына медицина ресурслары резервларын, шул исәптән үзенчәлекле фармакотерапия препаратларын инвентарьләштерергә һәм яңартырга.

4. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

аеруча мөһим, потенциаль куркыныч объектлар һәм тормыш эшчәнлеген тәэмин итү объектлары милекчеләренә дөнья чемпионатын үткәрә башлаганга кадәр Казан шәһәре территориясендә урнашкан әлеге объектларны үз иминлек

бүлекчәләре, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча «Охрана» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы постлары көчләре яки шартнамә нигезендә шәхси саклау предприятиеләре белән саклауны көчәйтүне;

«Казан Арена» акционерлар җәмгыяте генераль директорына дөнья чемпионатын үткәрү чорында эш итүче-тикшерүчеләрне «РАДЕКС-1503+» дозиметры белән тиешле санда тәэмин итүне һәм спорт чаралары үткәрү объектларындагы тикшереп үткәрү пунктларында (тикшерү шатерларында) дозиметрия тикшерүен үткәрүне оештыруны;

«РосАтом» дәүләт коорпорациясенең «РосРАО» радиоактив калдыклар белән эш итү предприятиесе» федераль дәүләт унитар предприятиесенә караган «Идел буе территориаль округы» филиалының Казан бүлеге директорына:

мөмкин булган гадәттән тыш хәлләргә җавап бирү максатларында, авария төркеме әзер булуны;

авария төркемен комплектлауны, җиһазландыруны, экипировкалауны һәм әзерләүне оештыруны;

радиоактив зарарлану билгеле булган объектларда (урыннарда) ионлаштырылган нурланыш чыганакларын (радиоактив матдәләрне) алуны һәм аларны чыгаруны гамәлгә ашыруны;

«Нэфис Косметикс» акционерлар җәмгыятенә, халыкны санитария ягыннан эшкәртү, шулай ук техника, биналар һәм территорияләрне махсус эшкәртү буенча мөмкин булган эшләрне башкару максатларында, йогышсызландыру матдәләр запасын булдыруны;

дөнья чемпионаты объектлары, аэропортлар, автовокзаллар, елга портлары һәм тимер юл станцияләре җитәкчеләренә (милекчеләренә) үз карамагындагы вокзалларны һәм портларны радиация мониторингын, химик һәм биологик мониторингны үткәрү өчен кирәкле приборлар һәм җайланма белән җиһазландыруны, әлеге объектларга һәм йөк терминалларына пассажирлар һәм йөкләр килгәндә радиациядән, химик куркыныч матдәләрдән һәм биологик саклануны тикшерүдә тотуны көчәйтүне;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына, базасында гражданнар оборонасы объектлары, йогышсызландыру командалары һәм штаттан тыш территориаль һәлакәттән коткару формированиеләре булдырылган Татарстан Республикасы оешмалары белән, шулай ук Татарстан Республикасының күзәтү һәм лаборатория тикшерүе челтәренә керүче учреждениеләр белән берлектә, үз вәкаләтләре кысаларында:

санитария ягыннан эшкәртүнең территориаль пунктлары, киемнәрне һәм техниканы махсус эшкәртү станцияләре, шулай ук лабораторияләр әзер булуны;

Казан шәһәрендә радиациядән, химик куркыныч матдәләрдән һәм биологик саклануны тикшерүдә тотуны оештыруны;

радиацияле, химик һәм биологик куркыныч объектлар җитәкчеләренә (милекчеләренә) дөнья чемпионатын үткәрү вакытында:

Казан шәһәре территориясе буенча ионлаштырылган нурланыш чыганакларын, радиацияле, химик һәм биологик (бактериологик), авария хәлендәге химик куркыныч, агулы һәм шартлагыч матдәләрне ташуны туктатуны;

авария хәлендәге химик куркыныч матдәләр запаслары күләмнәрен, егәрлекне киметмичә, җитештерүне тәэмин итә торган дәрәҗәгә кадәр киметүне;

мөмкин булган гадәттән тыш хәлләргә җавап бирү максатларында, газдан коткаручы объект формированиеләре әзер булуны;

газдан коткару формированиеләре һәм штаттан тыш һәлакәттән коткару формированиеләрен комплектлауны, җиһазландыруны, экипировкалауны һәм әзерләүне оештыруны, радиациядән һәм химик куркыныч матдәләрдән саклануны тикшерүнең техник чараларын тикшерүне;

мөмкин булган гадәттән тыш хәлләрне локальләштерү һәм бетерү өчен газдан коткаручы объект формированиеләрен җибәрүне;

кунакханәләр һәм дөнья чемпионаты кунаклары һәм анда катнашучылар яшәгән урыннар җитәкчеләренә (милекчеләренә) радиациядән саклануны тикшерүне оештыру өчен үз карамагындагы кунакханәләрне һәм яшәү урыннарын приборлар һәм җайланма белән җиһазландыруны.

5. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына бу карар белән расланган Радиация характерындагы, химик һәм биологик характердагы хәлләр (гадәттән тыш хәлләр) барлыкка килгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының федераль башкарма хакимият органнырының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибенә таянып эш итәргә, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына аңа таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

6. Дөнья чемпионатын әзерләү һәм үткәрү чорында радиациядән, химик куркыныч матдәләрдән һәм биологик саклануны һәм аларны тикшерүдә тотуны оештыру чыгымнарын тиешле финанс елына бюджетлар турындагы законнар (карарлар) нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм җирле бюджетлар акчасы, шулай ук оешмалар акчасы исәбеннән гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

7. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин